| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘТӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ<br>423737, Әтәс авылы, Үзәк ур., 75, а йорты<br>e-mail:AktSik-Akt@yandex.ru | | СОВЕТ АТЯСЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>423737, село Атясево, ул. Центральная, д. 75, а<br>e-mail:AktSik-Akt@yandex.ru |
|---|---|---|

КАРАР　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　РЕШЕНИЕ

20 июнь 2025 ел　　　　　　　　　　　　　　　　　　№9

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына вәкаләтләрне тапшыру турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Әтәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Әтәс авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Советына Актаныш муниципаль районы Әтәс авыл җирлеге Башкарма комитетының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрен Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру мәсьәләсен карарга тәкъдим итәргә:

- җирлек муниципаль милкендәге мөлкәт белән идарә итү, муниципаль милек объектларын файдалануга бирү, алар белән эш итү һәм арендалау мәсьәләләрен хәл итү буенча;

- җирлек территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау эшләрен башкарганда, объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан элек бирелгән вәкаләтләр буенча;

- муниципаль милектәге җирләрдән рациональ файдалануны һәм саклауны планлаштыруны һәм оештыруны гамәлгә ашыру;

- җирлекнең муниципаль милкендәге җир кишәрлекләрен законнарда билгеләнгән тәртиптә бирү һәм тартып алу, шул исәптән сатып алу юлы белән дә;

- Җирлек җирләреннән файдалануга җир контролен гамәлгә ашыру;

2. Актаныш муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимнәрне кабул иткән очракта, Актаныш муниципаль районының Әтәс авыл җирлеге башкарма комитетына:

- Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә.

3. Актаныш муниципаль районы Әтәс авыл җирлеге Советының 2006 елның 17 июлендәге 7.1 номерлы карарының 1 пунктчасының икенче абзацын һәм 2 пунктчасының 1 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Әтәс авыл җирлеге Советы рәисе:　　　　　　　　　　　　А.М.Шарипов